СТАРОАЙМАНОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423739, село Старое Айманово, ул.Новая,5А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423739, Иске Айман авылы, Яна ур..,5А

Тел/факс (885552)34452
saym.akt@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
15 «Января»2022

КАРАР
№ 2

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительләр советы турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл бирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча Попечительләр советы турындагы нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске айман авыл җирлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча Попечительләр советы составын расларга (кушымта).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Айман җирлеге башлыгы М.Р.Ахметханов